ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

# УРТА ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮ УКУ ЙОРТЛАРЫНЫҢ РУС ТЕЛЛЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН ҮРНӘК ЭШ ПРОГРАММАСЫ

# “ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ” ПРЕДМЕТЛАРЫ БУЕНЧА

КАЗАН
2017

ББК 74.268.1Тат
У 69

ТРМҮИ ректоры Р.Р. Бәдриеваның гомуми редакциялегендә

**“Татар теле һәм сөйләм культурасы”** предметына үрнәк программа Федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә һөнәри белем алучы _____________ белгечлеге өчен төзелде.

***Төзүче учреждение:*** _________
***Программаны төзүче авторлар:***

1. Гайнетдинова Гөлнара Рәшит кызы, Казан педагогия көллиятенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
2. Галимова Фәйрүзә Аксан кызы, Түбән Кама педагогия көллиятенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
3. Кәримова Гөлсинә Хисмәтулла кызы, Е.Н. Батенчук исемендәге Кама төзелеш көллиятенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
4. Хайрутдинова Зөлфия Рафик кызы, Түбән Кама эретеп ябыштыру-монтажлау көллиятенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.
5. Шайхатарова Эльмира Гафурҗан кызы, Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумының татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

**Фәнни җитәкче:** Шәмсетдинова Рәсимә Равиловна, ТР Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филол.фәннәре канд., доцент, РФ Югары мәктәбенең атказанган хезмәткәре.
**Рецензентлар:** Фәттахова Рузилә Фердависовна, ТР Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филол. фәннәре канд.; Нигъмәтҗанова Фәния Мәсгут кызы, Татарстан Республикасы урта һөнәри белем бирү уку йортларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының методик берләшмәсе җитәкчесе, Казан сәүдә-икътисад техникумының югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

**© ТРМҮИ, 2017**

**ЭЧТӘЛЕК**

АҢЛАТМА ЯЗУЫ ........................................................................................... 4
“ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ” ПРЕДМЕТЫНА ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКА ........................................................................................ 5
УКУ ПЛАНЫНДА “ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ”НЫҢ УРЫНЫ ........................................................................................................ 7
УКУ ҮЗЛӘШТЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ ................................................................ 7
УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ ........................................................ 9
ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ ........................................................................ 13
ҮРНӘК ТЕМАТИК ПЛАН ............................................................................. 13
СТУДЕНТЛАРНЫҢ УКУ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ ХАРАКТЕРИСТИКА ......... 13
УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ МЕТОДИК ҺӘМ МАТЕРИАЛЬ-ТЕХНИК БАЗАСЫ ........................................................................................................ 15
ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ ......................................... 16

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Базар икътисады шартларында Россиянең демократик, хокукый дәүләт буларак үсеше һәм телләр өйрәнүгә максатчан Федераль программа кабул ителү гражданнарның сөйләм культурасына югары таләпләр куя. Укытуның максаты җәмгыять тарафыннан куелган социаль заказ белән билгеләнә. Татарстан Республикасында белем бирү системасының төп бурычы – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы билингваль (полилингваль) шәхес тәрбияләү.

Тел һәм сөйләм – бер-берсеннән аерылгысыз икесе ике күренеш. Билгеләнгән коммуникатив максатка ирешү барышында тел берәмлекләрен тирәнтен белү белән беррәттән, төрле тормыш ситуацияләрендә әлеге берәмлекләрдән оста, уңышлы һәм нәтиҗәле куллана белү хәзерге заман таләбе.

"Татар теле һәм сөйләм культурасы" предметын өйрәнү **максаты:**

- һөнәри белем бирү кысаларында язма һәм әйтмә сөйләм культурасына ия булган белгеч әзерләү;
- студентларны татар теленең төп берәмлекләре, нормалары белән таныштыруны дәвам итү, аларны гамәлдә дөрес һәм максатчан куллану күнекмәсен камилләштерү;
- татар сөйләменең коммуникатив һәм этик үзенчәлекләрен ачу һәм, әлеге үзенчәлекләрне истә тотып, татарча нәтиҗәле сөйләм төзү күнекмәсен камилләштерү;

Предметның **бурычлары**:

- белгечләргә татар теле һәм сөйләм культурасы турында системалы белем һәм туган телнең аваз төзелеше, сүзлек хәзинәсе, грамматикасы, стилистикасы, сөйләмнең тел-сурәтләү чаралары турында белемнәрне тирәнәйтү;
- әдәби тел нормаларын тулысынча үзләштерү һәм аларны таный белү сәләтен камилләштерү;
- төрле ситуацияләрдә аралашу-сөйләшү үзенчәлекләрен гамәли үзләштерү;
- тел байлыгыннан ситуацияләргә һәм стильләргә мөнәсәбәтле файдалана белү;
- үзләштерелгән материалны логик эзлеклелектә аңлата белү;
- аралашуның сөйләмнән башка чараларын файдалану, аларның психологик, милли үзенчәлекләрен таный белү;
- сәнгатьле сөйләм осталыгын камилләштерү;
- әдәпле һәм әдәпсез сөйләм үзенчәлекләрен аера белү;
- лингвистик текст җирлегенә үтеп кереп, сөйләм хаталарын барлау, аларның барлыкка килү сәбәпләрен аңлату һәм хаталарны төзәтү күнекмәләрен булдырырга ирешү;
- уку йортында формалаштырылган белем һәм күнекмәләрне һөнәри

эшчәнлектә кулланырга әзерләү;

- логик фикерләү, иҗат итү сәләтләрен үстерү, камилләштерү;
- мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен камилләштерү һ.б.

Программаның тел берәмлекләрен өйрәнүне һәм аларны шул ук вакытта турыдан-туры сөйләмнең эчтәлеген, идеясен ачу юнәлешендә, сөйләмнең стиленә, жанрына туры китереп дөрес куллануны күздә тотып төзелүе студентларның коммуникатив, лингвистик (тел), этномәдәни компетенцияләрен формалаштыруга юнәлтелгәнен билгели.

Әлеге программа студентларга татар теле һәм сөйләм культурасын укыту буенча эш программаларын төзү өчен нигез булып тора: ул укыту предметының мәҗбүри өлешен билгели. Эш программаларына, уку йортының эш үзенчәлеген, укучыларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, уку материалын өйрәнүгә сәгатьләр саны бүленешен һәм материалны өйрәнү эзлеклелеген билгеләүдә, эчтәлекне киңәйтүдә, шулай ук укучыларның коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру юлларын ачыклауда укытучылар үзгәрешләр кертә алалар. Бу үзгәрешләр эш программаларының аңлатма язуында чагылыш табарга тиеш.

Программа дәүләт контроле һәм белем сыйфатын билгеләү системасы өчен нигез булып тора.

## “ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ” ПРЕДМЕТЫНА ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКА

Танып белү чарасы буларак татар теле һәм сөйләм культурасы укучыларның зыялылык һәм иҗади сәләтләрен, абстракт фикерләүләрен, хәтерләрен һәм образлы күзаллауларын, мөстәкыйль уку (өйрәнү) эшчәнлеге күнекмәләрен формалаштыра, үзбелем алу, шәхес буларак үсешне тәэмин итә.

Һөнәри белем бирү учреждениеләрендә “Татар теле һәм сөйләм культурасы” предметы белем бирү системасының төп үсеш юнәлешенә – системалы-эшчәнлекле юнәлешнә нигезләнгән. Системаны барлыкка китерә торган төп компонент – нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре дип билгеләнелә. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик нигез барлык фәннәрне укыту системасына да, шул исәптән, татар теле һәм сөйләм әдәбенә дә карый. Ул, үз чиратында, коммуникатив, тел һәм лингвистик һәм этномәдәни компетенцияләрне формалаштыруны һәм үстерүне тормышка ашыра.

*Коммуникатив компетенцияләр:*

- сөйләм эшчәнлегенең бөтен төрләренә (тыңлау, уку, сөйләшү, язу) ия булу;
- телдән һәм язма сөйләм әдәбе нигезләренә ия булу;
- сөйләм максатыннан чыгып, тел берәмлекләрен нәтиҗәле куллана белү;

- сөйләм ситуациясенә карап, аралашу барлыкка килсен өчен, тел чараларын махсус сайлый белү;
- телдән һәм язма сөйләмне аңлау һәм аның эчтәлеген тиешле күләмдә сөйләп бирү;
- төрле стильдә, жанрда, типта бәйләнешле сөйләм төзү.

*Тел һәм лингвистик компетенцияләр:*

- иҗтимагый күренеш һәм тамгалар системасы буларак тел турындагы белемнәрне системалаштыру;
- язма һәм әйтмә сөйләмдә әдәби тел нормаларын (орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик, стилистик, пунктуацион) белү, кисәтү;
- төрле сүзлекләр белән эшли белү күнекмәләрен үстерү;
- студентларның сүз хәзинәсен баету һәм сөйләмнәренең грамматик төзелешен камилләштерү.

*Этномәдәни компетенцияләр:*

- телне милләтнең мәдәни чагылышының бер формасы буларак тану;
- татар халкының тарихы һәм тел үсеше арасында бәйләнешләрне аңлау;
- татар теленең милли-мәдәни үзенчәлекләрен белү;
- милли сөйләм әдәбе нормаларын белү;
- милләтара аралашу әдәбенә ия булу.

“Татар телен һәм сөйләм культурасы” дисциплинасы программасына һөнәри уку йортының белем бирү юнәлешенә, студентларның белем дәрәҗәсенә карап, программаның эчтәлеген, сәгатьләр санын, аерым темаларны, гамәли эшләрнең характерын, күләмен үзгәртергә мөмкин.

Татар телен һәм сөйләм культурасын үзләштерү барышында студентларның гомуммәдәни, тәрбияви үсеш, тормышка яраклашу, һөнәри әзерлек мәсьәләләре хәл ителә.

Беренче чиратта, татар теле һәм сөйләм культурасы дәресләре тел системасын, аның үзенчәлекләрен күзаллаган, милли үзаңга ия, милли менталитетны һәм психологияне аңлаган, заман таләпләренә җавап бирерлек күпкырлы шәхесләр тәрбияләүгә юнәлгән булырга тиеш. Һөнәри юнәлештә белем алучы студентларга татар телендә иркен сөйләшергә, аралашырга, эзлекле итеп уйлый белергә, дөрес язарга һәм укырга өйрәтүдә гомумдидактик (фәннилек, дәвамчанлык, күрсәтмәлелек, укытуның тормыш белән бәйләнеше, тарихилык һ.б.), гомумметодик (коммуникатив, ситуатив-тематик һ.б.), хосусый методик (сүзләрне сайлау принцибы, аваз белән хәреф арасындагы аерманы төшендерү принцибы һ.б.), лингвистик (функциональ, стилистик аерымлау, бүлекара бәйләнеш принциплары) һәм психологик принципларга таянырга кирәк.

Татар теле һәм сөйләм культурасын өйрәнү укучыларның предметны югарырак дәрәҗәдә өйрәнүләрен күздә тота. Бигрәк тә, сөйләмнең функциональ стильләрен һәм сөйләм ситуациясенә мөнәсәбәтле тел берәмлекләрен, чараларын өйрәнү һәм аралашуда нәтиҗәле куллануга игътибар ителә. Программаның үрнәк эчтәлегендә сөйләм юнәлешендәге

темаларга (“Сөйләм һәм тел”, “Функциональ стильләр” һ.б.) сәгатьләр саны күбрәк каралган. Мөстәкыйль эш, төрле формадагы иҗади эшләргә, рефератлар, шәхси проектлар башкаруга игътибар ителгән.

Предметны үзләштерү барышында укучыларда сөйләмнең коммуникатив сыйфатын анализлый белү күнекмәләре формалаша, сөйләм әдәбеннән белемнәре тирәнәя. Шуңа күрә, тел берәмлекләрен сөйләм яссылыгында анализлау, сөйләм ситуациясенә мөнәсәбәттә һәм нәтиҗәле аралашу максатыннан аларны куллануга игътибар итү бик мөһим. Мәсәлән, лексик һәм грамматик синонимия, татар телендә сүзнең җөмләдәге урыны, аның стилитик бизәге, телнең сәнгати сурәт чаралары, сөйләм техникасы һәм башкалар киңрәк өйрәнелә. Билгеле, һөнәри уку йортының белем бирү юнәлешенә карап, теге яки бу темаларның эчтәлеге үзгәрергә мөмкин. Шуңа нигезләнеп, аларны алыштыру, сәгать саннарында үзгәрешләр булырга мөмкин.

“Татар теле һәм сөйләм культурасы” дисциплинасы дифференциаль зачет белән тәмамлана.

**Укыту программасының куллану өлкәсе**

“Татар теле һәм сөйләм культурасы” үрнәк программасы һөнәри белем бирү уку йортларында кулланырга тәкъдим ителә.

## УКЫТУ ПЛАНЫНДА “ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ”НЫҢ УРЫНЫ

“Татар теле һәм сөйләм культурасы”н өйрәнү өчен сәгатьләр саны уку планының вариатив өлешеннән алына. Дисциплина гомум гуманитар, социаль-экономик циклга карый.

## УКУ ҮЗЛӘШТЕРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ

“Татар теле һәм сөйләм культурасы”н укытуның көтелгән нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

- *шәхси:*
    - гасырлар дәвамында халык тарафыннан тупланган мәдәни һәм әхлакый кыйммәтләрне чагылдыручы һәм саклаучы буларак, туган телгә, башка милләтләр мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләү: милләт тарихы һәм теле арасында бәйләнешләрне аңлау;
    - шәхес буларак уңышлы социальләшүдә туган телнең әһәмиятле ролен аңлау;
    - милли мәдәниятнең күренеше буларак телнең чисталыгын саклауга теләк булдыру, телнең эстетик кыйммәтен тану;
    - күпмәдәни дөньяда үз урыныңны аңлау;
    - сөйләмгә үзконтроль булдыру; телдән һәм язма сөйләмеңне тел сурәтләү чаралары һәм коммуникатив максатка ирешү ягыннан үзбәяләү;
    - мөстәкыйль, иҗади һәм җаваплы эшчәнлеккә әзерлек һәм

сәләтлелек;
  - үз сөйләмеңне күзәтү нигезендә бәяли алу, тел һәм сөйләмне камилләштерүгә ихтияҗ.
- *метапредмет*
  - сөйләм эшчәнлегенең бөтен төрләренә дә ия булу: аудирование, аңлап уку, сөйләү, язу;
  - тел берәмлекләрен һәм чараларын белү – үз фикереңне дөрес, төгә, логик эзлеклелектә сөйли-яза белү; алган белемнәрне һәм күнекмәләрне тел кренешләрен анализлаганда предметара югарылыгында куллану;
  - әдәпле сөйләм күнекмәләрен туганнарың, иптәшләрең, балалар, өлкәннәр белән аралашуда, белем алуда, иҗтимагый файдалы хезмәттә, уку-тикшеренү, проект һәм башка эш төрләрендә куллану;
  - төрле ситуацияләрдә шәхесара, мәдәниятара аралашуда сөйләм әхлагы нормаларын саклау;
  - мәгълүмати-танып белү эшчәнлегенә әзерлек һәм сәләтлелек;
  - төрле чыганаклардан төп кирәкле мәгълүматны таба, билгели һәм аны эшчәнлектә дөрес куллана белү.
- *предмет:*
  - татар әдәби теле нормалары турында төшенчәнең формалашкан булуы һәм алар турындагы белемнәрне сөйләмдә куллана белү;
  - тел һәм сөйләм арасындагы аерманы, фикерне формалаштыру һәм тапшыру чарасы буларак тел функцияләрен белү;
  - телдән һәм язма сөйләмнең үзенчәлекләрен белү;
  - иҗтимагый-мәдәни, уку-фәнни, эшлекле аралашуның төрле төрләре һәм жанрларында телдән һәм язма монологик, диологик формада үз фикереңне белдерү күнекмәләренең формалашкан булуы;
  - үз сөйләмен тел һәм коммуникатив, әхлак нормаларына нигезләнеп төзү күнекмәләренә ия булу;
  - үз сөйләмеңә үзанализ ясый, бәяли белү күнекмәләренә ия булу;
  - төрле төрдәге текстлар төзи белү: тезис, конспект, төрле эш кәгазьләре, аннотация, реферат, сочинение, шәхси проект һ.б.;
  - татар теленең сәнгати сурәтләү чаралар турында белү;
  - текстка лингвистик һәм әдәби анализ ясый белү: әдәби текстның темасын, идеясен, проблемасын, образларны билгели белү һәм аларга үз мөнәсәбәтеңне телдән һәм язмача дәлилле белдерә белү;
  - текстның жанрына, стиленә мөнәсәбәттә аңа анализ ясау күнекмәсенә ия булу;

## УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

### Кереш

Татар теле һәм сөйләм культурасы дисциплинасы. Гомумкультураның бер өлеш буларак, тел һәм сөйләм культурасы. Гомумтел белеменең бер тармагы буларак, сөйләм культурасы. Татар теле һәм сөйләм культурасы дисциплинасының өйрәнү объекты, максаты, бурычлары. Гомумтел белемендә сөйләм культурасы өлкәсенең өйрәнелү дәрәҗәсе.

### Тел һәм сөйләм

Тел һәм сөйләм. Тел һәм сөйләмнең төп берәмлекләре, функцияләре. Тел һәм сөйләм арасында аерма.

Сөйләмгә мөнәсәбәтле ситуацияләр (яссылыклар) һәм аларның төрләре. Ситуацияләргә күзәтү.

Сөйләм ситуациясендә сөйләм элементлары: сөйләүче, тыңлаучы, сөйләмнең темасы, вакыты, урыны, максаты, сәбәбе. Аларга күзәтү.

Сөйләм төрләре. Телдән һәм язма сөйләм үзенчәлекләре. Телдән һәм язма сөйләм төзү күнегүләре.

### Сөйләм компетентлыгы

Сөйләм компетентлыгы турында төшенчә. Һөнәри сөйләм культурасы.

Сөйләмнең иҗтимагый аспектлары. Сөйләм дөреслеге. Сөйләмнең эчтәлекле булуы. Сөйләм төгәллеге. Сөйләм аныклыгы. Сөйләм чисталыгы. Сөйләмнең сәнгатьлелеге, сыгылмалыгы Сөйләмнең байлыгы, матурлыгы һәм анда тел чараларын куллану. Сөйләмнең урынлы булуы.

### Сөйләм техникасы

Сөйләм техникасы. Сулыш алу, тавыш, дикция, интонация. Сөйләмдә басым. Сәнгатьле сөйләм өчен партитура төзү. Сәнгатьле уку.

### Сөйләмгә мөнәсәбәтле стиль ситуациясе

Стилистика. Стиль. Стилистика фәне турында төшенчә. Стилистиканың әһәмияте. “Вертикаль” яктан стильләр. Сөйләм үзенчәлекләре. Сөйләмнең функциональ стильләре. Әдәби сөйләм һәм язма стильләр, аларның төрләре. Фәнни, рәсми-канцелярия, иҗтимагый-публицистик, хатлар һәм матур әдәбият стиле. Стильләрнең кулланылыш сферасы.

Фәнни стиль. Фәнни стильгә хас үзенчәлекләр. Фәнни стиль жанрлары. Аннотация, доклад, реферат, шәхси проект, чыгарылыш квалификацион эш, автореферат язуга таләпләр.

Рәсми-канцелярия стиле. Рәсми-канцелярия стиленә хас үзенчәлекләр. Рәсми-канцелярия стиле жанрлары. Гариза, аңлатма, характеристика, беркетмә һ.б. язуга таләпләр.

Иҗтимагый-публицистик стиль. Иҗтимагый-публицистик стиль үзенчәлекләре. Төп жанрлары. Мәкалә язуга.

Хатлар стиле. Хатларның төрләре. Хатларның төрләренә карап, аларны язу стиле.

Матур әдәбият стиле. Матур әдәбият стилендәге текстларның төрләре, жанрлары. Әдәби әсәрләрнең композициясе. Әдәби әсәрләрнең теле.

### Текст. Текст төзелеше

Сөйләмнең төп өйрәнү объекты буларак текст. Текст һәм аның микро һәм макротекстка бүленүе. Текст һәм абзац. Текстның мәгънәви, коммуникатив, структур, грамматик бөтенлеге. Текст композициясе.

Сөйләмнең мәгънәви-функциональ типлары. Төрле типтагы (сурәтләү, фикерләү, хикәяләү) текстлар төзү. Сочинение язу.

Чит сөйләмле текст. Чит сөйләмне текст эчендә өйрәнү. Чит сөйләм турында төшенчә. Аның төрләре: туры сөйләм, кыек сөйләм, уртак сөйләм. Чит сөйләм төрләренең үзара мөнәсәбәте. Туры сөйләм һәм диалог. Туры сөйләмне кыек сөйләмгә һәм киресенчә әйләндерү. Туры сөйләм, кыек сөйләм, уртак сөйләм янында тыныш билгеләре.

### Сөйләмгә мөнәсәбәтле тел ситуациясе

### Татар теленең төп фонетик кануннары

Телнең фонетик берәмлекләре. Авазларны төркемләү. Сөйләмдә авазлар үзгәреше. Сингармонизм һәм әдәби әйтелеш, язылыш мәсьәләләре. Редукция һәм орфография. Аваз төшү яки өстәлү белән бәйле орфоэпик һәм орфографик нормалар. Тартыклар охшашлануы һәм орфоэпия, орфография. Авазларның чиратлашуы. Хәзерге татар әдәби теленең орфографик принциплары. Транскрипция. Фонетик анализ. Орфоэпик һәм орфографик сүзлекләр белән эш. Сүзлекләрдән файдалану алымнары.

### Лексика һәм сөйләм культурасы

Сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. Күчерелмә мәгънәле сүзләрнең стилистик кулланылышы. Сүз мәгънәләре. Сүзнең күпмәгънәлелеге. Күпмәгънәле сүзләр һәм сөйләм культурасы. Омонимнар. Омонимнарның төрләре. Омонимнарның стилистик кулланылышы. Синонимнар. Синонимнарның төрләре: сүзгә-сүз, грамматик, лексик-грамматик. Синонимнарның стилистик кулланылышы. Синонимнарны куллануда хаталар. Антонимнар һәм сөйләм культурасы. Контекстуаль антонимнар. Антонимнар һәм антитеза. Антонимнарның стилистик кулланылышы. Оксюмороннар һәм сөйләм культурасы.

Фразеология һәм сөйләм культурасы. Фразеологик берәмлекләрнең төп билгеләре һәм аларның төрләре. Фразеологизмнарның стилистикасы.

Фразеологик берәмлекләр. Аларны сөйләмдә куллану.

Татар теленең сүзлек составы һәм сөйләм культурасы. Килеп чыгышы ягыннан хәзерге татар теленең сүзлек составы. Татар теленең нигезе буларак гомумтөрки сүзләр.

Кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы. Татар теленең сүзлек составында актив һәм пассив катламнар. Искергән сүзләр буларак тарихи сүзләр һәм архаизмнар. Яңа сүзләр (неологизмнар) һәм аларның барлыкка килү юллары.

Татар телендә алынмалар. Татар телендә гарәп-фарсы, рус, европа телләреннән алынган сүзләр. Аларның сөйләмдә кулланылышы.

Кулланылыш сферасы ягыннан татар әдәби теленең сүзлек составы. Һөнәри лексика. Терминнар.

## Татар теленең төп грамматик кануннары

## Морфология һәм сөйләм культурасы

Исем һәм сөйләм культурасы. Исемнең лексик-грамматик мәгънәсе, морфологик категорияләре һәм синтаксик билгеләре. Исемнәрдә сан, тартым, килеш категорияләренең стилистик кулланылышы. Морфологик анализ.

Сыйфат һәм сөйләм культурасы. Сыйфатларның гомумиләшкән лексик-грамматик мәгънәсе, морфологик һәм синтаксик билгеләре. Асыл һәм нисби сыйфатлар. Сыйфат дәрәҗәләре. Морфологик анализ.

Рәвеш һәм сөйләм культурасы. Рәвешнең лексик-грамматик мәгънәсе, морфологик һәм синтаксик билгеләре. Рәвешләрнең мәгънә буенча төркемнәре һәм стилистик кулланылышы. Рәвеш төркемчәләре. Морфологик анализ. Сөйләмдә рәвешләрнең кулланылышы.

Сан һәм сөйләм культурасы. Саннарның лексик-грамматик мәгънәсе, морфологик үзенчәлекләре һәм синтаксик билгеләре. Саннарның лексик-грамматик төркемчәләре. Саннарның сөйләмдә кулланылышы. Саннарның язма сөйләмдә дөрес язылышы. Морфологик анализ.

Алмашлык һәм сөйләм культурасы. Алмашлыкның лекси-граммтик мәгънәсе, морфологик табигате һәм синтаксик билгеләре. Алмашлыкларның мәгънә буенча төркемчәләре. Алмашлыкларның сөйләмдә кулланылыш үзенчәлекләре. Морфологик анализ.

Фигыль һәм сөйләм культурасы. Фигыльнең гомумиләшкән лексик-грамматик мәгънәсе, морфологик билгеләре һәм синтаксик функцияләре. Фигыльгә хас морфологик категорияләр. Фигыльләрнең грамматик-стилистик үзенчәлекләре.

Ярдәмче сүзләр һәм сөйләм культурасы. Бәйлекләр һәм теркәгечләрнең грамматик мәгънәләре, морфологик табигате, синтаксик функцияләре.

Модаль сүз төркемнәре һәм сөйләм культурасы. Кисәкчәләрнең лексик-грамматик мәгънәләре, морфологик табигате, грамматик функцияләре. Аларның төп мәгънәләре һәм төркемчәләре

Ымлыкларның лексик-грамматик, морфологик һәм синтаксик функциягә бәйле билгеләре. Ымлыкларның мәгънәви төркемчәләре. Стилистик кулланылышы.

Модаль сүзләрнен лексик-грамматик мәгънәләре, морфологик табигате һәм синтаксик функцияләре. Модаль сүзләрнең мәгънәләре һәм аларның җөмләдә кереш сүз буларак кулланылышы. Модаль сүз төркемнәре. Аларның сөйләмдә кулланылышы һәм дөрес язылышы.

## Татар теленең сүзьясалыш кануннары

Сүз төзелеше. Морфема: тамыр, кушымча. Нигез. Кушымча морфемаларны ялгау хаталары. Сүзьясалыш ысуллары. Тамыр, саф ясалма, кушма, парлы, тезмә, кыскартылма сүзләр. Сөйләмдә кыскартылма сүзләрне ясау һәм куллану. Сүзләргә морфемик һәм сүзьясалыш ысулларына анализ.

## Татар теленең синтаксик кануннары

Синтаксис һәм аның өйрәнү объекты буларак сөйләм төзелеше. Төп синтаксик берәмлекләр. Сөйләм һәм фикерләүнең төп берәмлеге буларак җөмлә. Җөмләгә билгеләмә. Җөмләнең төп үзенчәлекләре буларак хәбәрлек

һәм модальлекнең белдерелүе. Сөйләмдә сүзләр һәм җөмләләр бәйләнеше. Сөйләмне оештыруда тезүле һәм ияртүле бәйләнеш.

Сүзтезмә. Сүзтезмәләрнең төрләре. Сүзтезмәләрнең синонимлыгы.

Гади җөмлә һәм аның стилистик кулланылышы. Җөмләнең грамматик кисәкләргә бүленеше. Җөмлә кисәкләре. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Җөмләнең модаль кисәкләре.

Сөйләмдә тиңдәш кисәкле җөмләләр. Тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр, тыныш билгеләре. Сөйләмдә тиңдәш кисәкләрне куллану.

Сөйләмдә аерымланган иярчен кисәкле җөмләләр. Язма сөйләмдә аерымланган иярчен кисәкләр янында тыныш билгеләре.

Җөмләдә сүз, сөйләмдә җөмләләр тәртибе. Җөмләдә сүз тәртибе.

Җөмлә төрләре һәм аларның сөйләмдә кулланылышы. Җөмләләрне төркемләү. Җөмләләрне төркемләү принциплары. Төрле типтагы җөмләләрне сөйләмдә куллану.

Кушма җөмлә аның стилистик кулланылышы. Җөмләләрнең синонимлыгы.

**Пунктуация һәм сөйләм культурасы**

Тыныш билгеләре. Аларның язудагы роле. Тыныш билгеләрен төркемләү. Тыныш билгеләре һәм интонация. Аларның функцияләре. Тыныш билгеләрен кую кагыйдәләре. Текстка пунктуацион анализ.

## ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

Укыту предметын үзләштерү өчен үрнәк программада тәкъдим ителгән сәгатьләр саны.

Укучыларның максималь уку сәгатьләр саны – 175

Шулар эчендә:

- мәҗбүри аудитор сәгатьләр саны (гамәли сәгатьләр белән бергә) – 117
- мөстәкыйль эш сәгатьләр саны – 58

## ҮРНӘК ТЕМАТИК ПЛАН

| **Бүлекләр исемлеге** | **Сәгатьләр саны** |
|---|---|
| Кереш. | 2 |
| Тел һәм сөйләм | 6 |
| Сөйләм компетентлыгы | 2 |
| Сөйләм техникасы | 4 |
| Сөйләмгә мөнәсәбәтле стиль ситуациясе | 24 |
| Текст. Текст төзелеше | 14 |
| Сөйләмгә мөнәсәбәтле тел ситуациясе<br>Татар теленең төп фонетик кануннары | 4 |
| Лексика һәм сөйләм культурасы | 24 |
| Татар теленең төп грамматик кануннары<br>Морфология һәм сөйләм культурасы | 13 |
| Татар теленең сүзьясалыш кануннары | 2 |
| Татар теленең синтаксик кануннары | 14 |
| Пунктуация һәм сөйләм культурасы | 6 |
| **Аттестация формасы:** ***дифференциаль зачет*** | 2 |
| **Мөстәкыйль өйрәнү өчен сәгатьләр саны** | 58 |
| **Барлыгы** | **175** |

## СТУДЕНТЛАРНЫҢ УКУ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ ХАРАКТЕРИСТИКА

| **Укыту эчтәлеге** | **Студентларның уку эшчәнлегенә характеристика** |
|---|---|
| Кереш | телне һәм сөйләм культурасын үзләштерүнең әһәмиятле фактор булуын дәлилләүче мисаллар китерү; татар теленең җәмгыятьтәге роле турында фикерләрне формалаштырып җиткерү; тема буенча фикер алышу |
| Тел һәм сөйләм | тел һәм сөйләм үзенчәлекләрен үзләштерү; алар арасында уртак һәм аермалы якларын билгеләү, тел һәм сөйләм арасында бәйләнешне ачыклау; төрле ситуациядә әңгәмә оештыру; сөйләм элементларын истә тотып аралашу, телдән һәм язма сөйләм төзү күнегүләре башкару |
| Сөйләм компетентлыгы | һөнәри сөйләм культурасын үзләштерү; дөрес, төгәл, чиста, логик эзлекле, аңлаешлы, сәнгатьле сөйләм төзү; |

| | |
|---|---|
| | билгеле бер темага җәмәгатьчелек каршында чыгыш ясау; |
| Сөйләм техникасы | сөйләм төрләренә һәм формаларына бәя бирү; сөйләмдә җибәрелгән хаталарны табып, аларны төзәтә белү; текстны, өзекләрне сәнгатьле уку |
| Сөйләмгә мөнәсәбәтле стиль ситуация-се | сөйләм стильләрен аера белү; стиль таләпләрен үтәп язма эшләр башкару, эш кәгазьләрен дөрес язу |
| Текст. Текст төзелеше | текст төзү үзенчәлекләрен үзләштерү; төрле типтагы текстлар төзү; чит сөйләмле текст төзү; туры сөйләмне кыек сөйләмгә һәм киресенчә әйләндерү; язма эшләр башкару; тестка лингвостилистик анализ ясау; текст буенча үз фикереңне формалаштырып, тыңлаучыга җиткерү |
| Сөйләмгә мөнәсәбәтле тел ситуациясе. Татар теленең төп фонетик кануннары | фонетик анализ ясау; таблицадан, презентацияләрдән, дәреслекләрдән фонетика буенча мәгълүматлар табу; төрле эшчәнлектә орфоэпик сүзлекләрне куллану, авазларны дөрес әйтеп сөйләү |
| Лексика һәм сөйләм культурасы | лексик һәм грамматик мәгънәләрен аеру; текста омоним, синоним, антоним, фразеологизмнарның стилистик бизәлешен билгеләү; публицистикада, матур әдәбиятта лексик һәм фразеологик сурәтләү чараларын тану, бәяләү; төрле төрдәге сүзлекләр белән эшләү; сүзгә лингвистик анализ ясау; татар теленең бай сүзлек хәзинәсен сөйләмдә нәтиҗәле куллану |
| Татар теленең төп грамматик кануннары. Морфология һәм сөйләм культурасы | текстан өйрәнелә торган тел күренешләренең кулланылышларын күзәтү һәм тикшерү; сүз төркемнәренең грамматик-стилистик үзенчәлекләрен билгеләү |
| Татар теленең сүзьясалыш кануннары | сөйләм төзүдә сүзьясалыш кануннары йогынтысын ачыклау, кушымча ялгау закончалыкларын белү, төзелеше ягыннан сүзләрнең төзелешен аера белү; сүзләргә морфемик һәм сүзьясалыш ысулларына анализ ясау |
| Татар теленең синтаксик кануннары | сөйләм төзегәндә төп синтаксик кануннарны саклау; җөмлә, җөмлә төзелешенең синонимлыгын үзләштерү |
| Пунктуация һәм сөйләм культурасы | язма сөйләмдә тыныш билгеләрен кую кагыйдәләрен үзләштерү; грамоталы язу; текстка пунктуацион анализ; хаталарны күрә һәм төзәтү |

# УКЫТУ ФӘНЕНЕҢ МЕТОДИК
# ҺӘМ МАТЕРИАЛЬ-ТЕХНИК БАЗАСЫ

Татар теле һәм сөйләм әдәбе предметын укыту махсус җиһазландырылган, Интернет челтәренә тоташтырылган кабинетның булуын таләп итә. Укыту барышында түбәндәге материаль-техник чараларны файдалану мөмкинлеге күздә тотыла: ПК; мультимедиале проектор; электрон дәреслекләр; электрон китапханә; УМК; дәреслекләр; сүзлекләр.

## ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


***Төп чыганаклар:***

1. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (2004 ел, 1 июль).
2. Абдуллина, Р. С. Сөйләм культурасы / Р.С. Абдуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015.
3. Сафиуллина, Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле / Сафиуллина – Казан: Мәгариф, 2002.
4. Сафиуллина, Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле (күнегүләр җыентыгы) / Ф.С. Сафиуллина – Казан: Мәгариф, 2002.

***Өстәмә чыганаклар:***

1. Абдуллина, Р.С. Риторика һәм интонация / Р.С. Абдуллина. – Чаллы, 1999.
2. Абдуллина,Р.С. Алфавитка бәйле орфография һәм орфоэпия мәсьәләләре. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2006.
3. Абдуллина, Р.С. Хәзерге татар теленең орфографиясе һәм орфоэпиясе. – Казан: Мәгариф, 2009.
4. Әхмәтҗанов, Р. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Тат. кит. нәшр, 2001.
5. Валиев, З.В. Эш кәгазьләре үрнәкләре. Образцы деловых бумаг / З.В. Валиев. – Казань: Тат. кн. издат., 1999.
6. Ганиев, Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы. – Казан: Мәгариф, 2009.
7. Галимуллина, Г.Р. Татар теле. Лексикология: таблицалар, схемалар, анализ үрнәкләре, күнегүләр, сүзлекчә. – К.: Мәгариф, 2007.
8. Исәнбәт, Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. 2 томда. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1989.1990.
9. Зәкиев, М.З. Татар теле синтаксисы. – Казан: Мәгариф, 2008.
10. Сафиуллина, Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. – Казан: Хәтер, 2000.
11. Сафиуллина, Ф.С. Татарча-русча фразеологик сүзлек. – Казан: Мәга-риф, 2001.
12. Сафиуллина, Ф.С., Ризванова Л.М. Омонимнар сүзлеге. Русчага тәрҗемә белән. – Казан: Хәтер, 1997.
13. Сафиуллина, Ф.С., Ризванова Л.М. Антонимнар сүзлеге.- Казан: Хәтер, 1998.
14. Сафиуллина, Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. – Казан: Хәтер, 2001.
15. Татар грамматикасы. – 1 т. – Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 1998.
16. Татар грамматикасы. Т.II. – М.: Инсан, К.: Фикер, 2002.
17. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005.
18. Татар теленең орфографик сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2010.
19. Татарча – русча – инглизчә фразеологик сүзлек. – Казан: Мәгариф,

2010.
20. Фасеев, Ф.С. Татар телендә терминология. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1980.
21. Харисов, Ф.Ф., Харисова Ч.М. Татр теленнән күнегүләр һәм тестлар. – Казан: Яңалиф, 2006.
22. Харисова, Ч.М. Татар теле: Теория, кагыйдәләр, күнегүләр. – Казан: Мәгариф, 2006.
23. Харисова, Ч.М. Татар теле. Анализ үрнәкләре: югары сыйныф укучылары, абитуриентлар, студентлар, укытучылар өчен ярдәмлек / Ч.М. Харисова. – Казан: Мәгариф, 2009.
24. Хәйруллина, А.Х. Дөрес сөйләргә өйрәнегез. – Казан: Казан нәшр., 1992.
25. Ханбикова, Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1999.
26. Хисамова, Ф.М. Татар теле морфологиясе. – Казан: Мәгариф, 2006.

***Интернет ресурлар:***

1. www.mon.tatar.ru
2. Татар теле һәм әдәбияты – Википедия ru.wikipedia.org›wiki / Татар теле
3. Мин татарча сөйләшәм www.proshkolu.ru
4. Tatar.com.ru: татар теле
5. Казан шәһәре администрациясенең рәсми сайты Week-end в Казани.
6. http://www.belem.ru/
7. http://www.tugantelem.narod.ru

УРТА ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮ УКУ ЙОРТЛАРЫНЫҢ
РУС ТЕЛЛЕ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ҮРНӘК ЭШ ПРОГРАММАСЫ

“ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ СӨЙЛӘМ КУЛЬТУРАСЫ”
ПРЕДМЕТЛАРЫ БУЕНЧА

Форм.бум. 60x84 $^1/8$. Гарнитура Таймс
Усл.печ.л. 2,3
Оригинал-макет подготовлен в редакционно-издательском отделе
Института развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
E-mail: irort2011@gmail.com